СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

№51 Алабуга шәһәре «30» март 2026 ел

Алабуга муниципаль районы Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2025 елның 11 декабрендәге 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьяларына таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2025 елның 11 декабрендәге 21 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

*1 өлештә:*

1 нче пунктта «4 460 598,4» саннарын «4 491 124,1» саннарына алмаштырырга;

2 нче пунктта «4 824 991,9» санын «5 006 429,0» санына алмаштырырга;

3 нчы пунктта «364 393,5» саннарын «515 304,9» саннарына алмаштырырга;

*3 өлештә:*

1 нче кушымтаның «2026 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаның «2026 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керем күләме» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

3) 4 статьяда:

3 нче кушымтаның «2026 елга Алабуга муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 1 нче таблицасындагы 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымтаның «2026 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 1 нче таблицасындагы 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаның «2026 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү» 1 нче таблицасындагы 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 пунктта 2025 елга район бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме «83 622,9» санын «91 509,0»; санына алмаштырырга.

4) «2026 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләме» 16 статьясы белән тулыландырырга һәм 10 нчы кушымтада бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү һәм туризм мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

Рәис урынбасары А.В. Косов